Республика Татарстан
**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-42-15
факс: (85593) 2-80-13

Татарстан Республикасы
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-15
факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » 05 2026 ел № 40

«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында»гы Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 20.03.2025 № 33-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында"гы 23.12.2023 ел, № 131-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында"гы 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында"гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2023 № 1743 карары, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы 14.08.2014 ел, № 42 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 04.10.2018 ел, № 33 карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Иҗтимагый фикер

алышулар уздыру турында»гы 21.05.2026 ел, № 01-09-12058 хатына бәйле рәвештә, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына кеше хокукларын, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, к а р а р  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында»гы боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар (алга таба - гавами тыңлаулар) үткәрүне билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында»гы боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем (алга таба - эшче төркем) төзергә.

4. Эшче төркем составын расларга:

Самонина С.П. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем җитәкчесе (килешү буенча);

Захаров А.Н. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, эшче төркем җитәкчесенең урынбасары (килешү буенча);

Латыйпова Г.А. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге җитәкчесе, эшче төркем секретаре (килешү буенча);

Эшче төркем әгъзалары:

Магамедова А.М. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);

Хөббәтова А.М. - Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе (килешү буенча);

Мусин М.Н. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге җитәкчесе (килешү буенча);

Нәбиуллин Р.М. - Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты (килешү буенча);

Солтанов Р.Н. - Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты (килешү буенча);

Әминова З.З. - Татарстан Республикасы Ютазы район Советының җирлекләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе.

5. Гавами тыңлауларны оештыручыга:

1) җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә;

2) «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында»гы Татарстан Республикасы

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру хакында хәбәрләр җибәрергә:

- әлеге рөхсәт соралган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең хокук ияләренә;

- әлеге рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә;

- әлеге рөхсәт сорала торган капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләренә.

3) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр әзерләргә;

4) әлеге пунктның 3 бүлегендә күрсәтелгән хәбәрнамәне Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган тәртиптә бастырып чыгарырга.

6. Гавами тыңлаулар үткәрү вакытын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге халкына аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлауларны уздыру вакыты бер айдан артмаска тиеш.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы
карарына кушымта
26. 05. 2026 ел № 40

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№__________

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

«_____»_____________20__

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында**
**ПРОЕКТ**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, "Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында"гы 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимнәрен исәпкә алып, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына индивидуаль торак зонасында Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Кәрәкәшле авыл җирлеге, Мирфатыйх Зәкиев урамы - «элемтә» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегендә индивидуаль торак төзелеше (Ж1) зонасында адресы буенча урнашкан 16:43:060103:758 номерлы, 195 кв.м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

2. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек секторына (Р.Ж. Зәйнуллина) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Территорияләрне үстерү департаментының Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә (А.А. Шәйдуллина) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгаруга җибәрүне тәэмин итәргә (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Территорияләрне үстерү**
**департаменты җитәкчесе** **А.И. Әхмәтҗанов**